КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2020 ел, 7 март г.Казань № б-511

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 31 май, б-985 нче боерыгы белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 8 апрель, б-671 нче; 2018 ел, 19 апрель, б-906 нчы; 2019 ел, 12 апрель, б-779 нчы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында эшкә сәләтле яшьтәге халыкның сәламәтлеген саклауны дәүләт тарафыннан җайга салу чаралары программасын эшләү буенча проект офисы составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

проект офисы составыннан А.Д.Гариповны, А.Р.Зариповны, Б.К.Мәҗитовны, И.Р.Һидиятовны чыгарырга;

проект офисы составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрының беренче урынбасары Альмир Рәшид улы Абашевны;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының дәвалау һәм профилактика ярдәме күрсәтү идарәсе башлыгы Елена Федоровна Әхмәтҗанованы;

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе Зилә Рәхимҗан кызы Вәлиеваны (килешү буенча);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә караган сәламәтлек саклау мәсьәләләре секторының баш киңәшчесе Светлана Хатыйп кызы Галиеваны;

югары белем бирүче «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең Идарә, икътисад һәм финанслар институтына караган социаль өлкәдә менеджмент кафедрасы доценты, Татарстан Республикасының хәйрия аң-белем бирү иҗтимагый оешмасы президенты Зөһрә Рәшид кызы Җиһаншинаны;

Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы җитәкчесе урынбасары Ольга Михайловна Краснованы (килешү буенча);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе башлыгы Гөлшат Рәдиф кызы Нигъмәтуллинаны;

Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәетгәрәй улы Сәлимгәрәевны;

Рафис Җәүдәт улы Хәбибуллинның вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе башлыгы (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин